Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советының алтмыш икенче утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«21» май 2020 ел — № 148

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 18 февралендәге 10-53/2139 номерлы бәяләмәсенә таянып, 2020 елның 14 маендагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен, 2020 елның 15 маендагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча **Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының 2015 елның 13 августында кабул ителгән 15 номерлы (2016 елның 12 гыйнварындагы 35 номерлы үзгәрешләр кертү белән) «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Генераль планына, электрон рәвештәге кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы — Р.Г. Баһауов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КОНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ КОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000842